КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 27 октябрь г.Казань № 868

«Балаларны карап тоту» дәүләт хезмәтенең сыйфат стандартын раслау турында

Дәүләт оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгән «Балаларны карап тоту» дәүләт хезмәтенең сыйфат стандартын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы карамагындагы махсус (коррекцияле) мәктәпләрдә (интернат мәктәпләрдә), шифаханә мәктәпләрендә (интернат мәктәпләрдә) яшәүче тәрбияләнүчеләргә хуҗалык-көнкүреш һәм санитария-гигиена хезмәте күрсәтүне, аларның туклануын, буш вакытларын, көнкүрешен һәм ялын тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2012 ел, 10 август, 693 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 27 октябрь, 868 нче карары белән расланды

«Балаларны карап тоту» дәүләт хезмәтенең сыйфат стандарты

## I. Дәүләт хезмәтен алучыларның категорияләре (шулай ук ташламалы)

Балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәтен алучылар (алга таба – дәүләт хезмәте) түбәндәгеләр:

сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, шул исәптән инвалидлык булган, Татарстан Республикасы карамагындагы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген алып баручы гомуми белем бирү оешмаларының интернатларында уку дәверендә яшәүче укучылар;

Татарстан Республикасы карамагындагы төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмаларның интернатларында уку дәверендә яшәүче укучылар;

озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен Татарстан Республикасы карамагындагы шифаханә тибындагы гомуми белем бирү оешмаларында укучылар (алга таба – шифаханә мәктәп-интернаты);

Татарстан Республикасы карамагындагы, «кадет мәктәп-интернаты» махсус атамасы булган гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмаларда төп гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар (алга таба – кадет мәктәп-интернаты).

## II. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең хокукый нигезе

2.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге норматив хокукый актлар, башка норматив актлар белән көйләнә:

Россия Федерациясе Конституциясе;

«Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Федераль Закон;

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясенең гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен бетерү эшләре буенча министрлыкның «Янгынга каршы саклану системалары. Эвакуация һәм чыгу юллары» СП 1.13130 кагыйдәләр җыелмасын раслау турында» 2020 елның 19 мартындагы 194 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитария табибының «Санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм СанПиН 2.4.2.1178-02 нормативларын гамәлгә кертү турында» 2002 елның 28 ноябрендәге 44 номерлы карары;

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Балалар һәм яшьләр ялын, аларны тәрбияләүне, укытуны һәм сәламәтләндерүне оештыруга карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән СП 2.4.3648-20 нче санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешманың уставы;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешманың локаль актлары.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән көйләнми.

## III. Дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен хезмәт алучыларга гариза һәм түбәндәге документларны тапшыру кирәк:

| Т/с | Документлар исемлеге | Документны бирүче оешма яки документны бирү өчен җаваплы затлар | Документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Дәүләт хезмәтен алучы ата-анасының (законлы вәкиленең) шәхесен таныклаучы документның күчермәсе | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 2. | Бала туу турында таныклыкның яки дәүләт хезмәтен алучының туганлыгын раслаучы документның күчермәсе | Гражданлык хәле актларын теркәүче органнар | законнар нигезендә |
| 3. | Опека яки попечительлек билгеләнүен раслаучы документның күчермәсе (кирәк булганда) | Опеканың территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 4. | Яшәү урыны буенча яисә беркетелгән территориядә булу урыны | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр | законнар нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | буенча баланы теркәү турындагы документның күчермәсе яисә яшәү урыны буенча теркәлүне рәсмиләштерү өчен документларны кабул итү турындагы белешмә (бала яисә беркетелгән территориядә яшәүче укырга кабул ителгән очракта яисә гомуми белем бирү программалары буенча укытуга өстенлекле алым хокукы кулланылган очракта) | министрлыгының территориаль органнары | |
| 5. | Чит ил гражданины яки гражданлыгы булмаган зат булып торучы баланың ата-анасы (законлы вәкиле) өстәмә рәвештә дәүләт хезмәтен алучының туганлыгын (яки баланың хокукларын законлы рәвештә тәкъдим итүне) раслаучы документны һәм баланың Россия Федерациясендә булу хокукын раслаучы документны күрсәтә | Чит ил дәүләтенең вәкаләтле органы яки Россия Федерациясенең вәкаләтле органы | законнар нигезендә |
| 6. | Чит ил гражданы яки гражданлыгы булмаган зат булган балада тирәюньдәгеләр өчен куркыныч тудыручы йогышлы авырулар булмавы турында Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләр биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законының 43 статьясының 2 өлешенә туры китереп расланган исемлек нигезендә медицина белешмәсе | Беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмасы | 1 ел |
| 7. | Интернатта яшәүгә каршы күрсәтмәләр булмавы турында медицина белешмәсе | Медицина оешмасы | 1 ел |

Гариза формасы кәгазь рәвешендә дәүләт хезмәтен алучы, аның әти-әнисе (законлы вәкиле) тарафыннан турыдан-туры оешмада алынырга мөмкин.

## IV. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм шартларына таләпләр

4.1. Дәүләт хезмәте дәүләт оешмаларында күрсәтелә.

4.2. Дәүләт хезмәте түбәндәге максатларда күрсәтелә:

укучыларны тәрбияләүдә гаиләгә ярдәм күрсәтү;

укучыларда мөстәкыйль тормыш күнекмәләре, социаль яклау һәм иҗади сәләтләрне һәрьяклап ачу формалаштыру;

укучыларның уку дәверендә дәүләт оешмаларында яшәү вакытында хуҗалык-көнкүреш һәм санитар-гигиена хезмәтләре, туклану, ял һәм күңел ачу белән тәэмин итү;

профилактик, дәвалау һәм тернәкләндерү чараларын үткәрүне тәэмин итү.

4.3. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләрне үз эченә ала:

хуҗалык-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү:

санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормаларга һәм дәүләт оешмасының җирле актларына туры китереп, укучыларны туклану белән тәэмин итү;

законнарда каралган очракларда укучыларны санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормаларына туры китереп йомшак һәм каты инвентарь, кием-салым, аяк киеме, ятак кирәк-яраклары белән тәэмин итү (дәүләт оешмасында яшәүче укучылар өчен);

укучыларның гигиена хезмәтләрен тәэмин итү, шул исәптән укучы дәүләт оешмасында яшәгән очракта шәхси гигиена әйберләре белән тәэмин итү, санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормаларына туры китереп;

укучыларның сәламәтлек торышын системалы күзәтүдә ярдәм итү;

укучыларның сәламәтлек торышына зарланулары булганда дәүләт оешмасының медицина хезмәткәрләренә яки медицина оешмаларына ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү, госпитализация өчен мөрәҗәгать итү;

укучыларны дәвалау-профилактика учреждениеләренә, медицина оешмаларына, медицина-социаль экспертиза оешмаларына озату кирәк булганда;

укучыларны медицина күрсәткечләре буенча дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр белән тәэмин итүдә ярдәм итү;

инвалид баланың индивидуаль тернәкләндерү программасы нигезендә тернәкләндерүнең техник чаралары белән тәэмин итүдә ярдәм итү;

сәламәтләндерү чараларын үткәрү;

зарарлы гадәтләр барлыкка килүен кисәтү һәм алардан котылу, наркомания, токсикомания һәм алкоголизмны профилактикалау, санитария-гигиена мәгълүматы бирү, инвалид балаларны тернәкләндерүнең индивидуаль программаларын дәвалау-физкультура чараларын үткәрү өлешендә үтәү;

социаль-психологик хезмәтләр, укучылар өчен социаль-психологик консультацияләр, коррекция-үстерү дәресләре үткәрү, инвалидлык белән укучыларны психологик-педагогик тернәкләндеү чараларын үткәрү өлешендә тернәкләндерүнең индивидуаль программаларын үтәү;

социаль-педагогик хезмәтләр, һөнәри юнәлеш бирү чаралары, укучыларның буш вакытын оештыру, социаль адаптация, эстетик тәрбия һәм укучыларның төрле эшчәнлек төрләренә иҗади сәләтләрен үстерү чараларын планлаштыру һәм гамәлгә ашыру.

4.4. Дәүләт хезмәтен алу вакытында укучыларның, аларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) хокуклары һәм бурычлары дәүләт оешмаларының уставлары һәм локаль актлары белән билгеләнә.

V. Дәүләт хезмәтен матди-техник тәэмин итүгә таләпләр

5.1. Дәүләт оешмасы көнкүрешне, ялны, массакүләм, шул исәптән спорт чараларын үткәрүне, медицина ярдәме күрсәтүне, туклануны, хуҗалык-көнкүреш һәм санитария-гигиена хезмәтләрен оештыру өчен кирәкле бүлмәләр, корылмалар белән тәэмин ителергә тиеш, алар санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормалары таләпләренә җавап бирергә тиеш.

Укучыларга хуҗалык-көнкүреш һәм санитария-гигиена хезмәтләре күрсәтү өчен бүлмәләр составына түбәндәгеләр керергә тиеш:

малайлар һәм кызлар өчен аерым йокы бүлмәләре;

үзләре әзерләнү өчен бүлмәләр;

юыну бүлмәләре, бәдрәфләр, душлар, гигиена бүлмәсе.

Күрсәтелгән бүлмәләрнең мәйданнары, аларны җиһазлар, каты, йомшак инвентарь белән комплектлау санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормаларына туры китереп билгеләнә. Җиһазлар, бүлмәләрнең бизәлеше һәм аларның эчтәлеге дәүләт оешмаларында эш режимын урнаштыруга, тотуга, оештыруга гигиена таләпләренә туры килергә тиеш.

Өстәлләр, тумбочкалар, караватларның арткы яклары, киштәләр һәм башка җиһазларның өслекләре шома, җиңел дымлы җыештыру һәм дезинфекцияләү өчен уңайлы булырга тиеш.

5.2. Дәүләт оешмаларының тирә-юнь территориясе санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормативлары таләпләренә туры килергә тиеш.

VI. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең куркынычсызлык таләпләре

6.1. Дәүләт оешмалары законнар белән билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак теркәлгән булырга һәм түбәндәгеләргә ия булырга тиеш:

юридик затны салым органында исәпкә куелу турында таныклык күчермәсен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына юридик зат турында язма кертү турында таныклык;

законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән устав;

законнарга ярашлы лицензияләнергә тиешле эшчәнлек төрләренә лицензияләр, рөхсәтләр.

6.2. Дәүләт оешмасының биналары һәм бүлмәләре «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары таләпләренә, санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормаларына туры килергә тиеш.

6.3. Җиһазлар, приборлар, аппаратура, инвентарь санитария-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормалары таләпләренә, шулай ук продукциянең тиешле төренә һәм рәвешенә законнарда билгеләнгән куркынычсызлык таләпләренә туры килергә, эксплуатация документларына ярашлы билгеләнгәнчә кулланылырга, техник яктан төзек хәлдә булырга тиеш.

6.4. Дәүләт оешмасы законнар белән билгеләнгән тәртиптә укучыларның тормышы, сәламәтлеге, хокуклары һәм ирекләре, законлы мәнфәгатьләре өчен җаваплы була.

## VII. Дәүләт хезмәтен алучылар өчен аның мөмкинлеген тәэмин итүче таләпләр

7.1. Дәүләт оешмасы Татарстан Республикасы территориясендә, укучылар һәм аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) өчен уңайлы булган транспорт өчен уңайлы урыннарда урнашырга тиеш.

7.2. Дәүләт хезмәте уку елы дәвамында дәүләт оешмасының җирле акты белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтелә.

7.3. Дәүләт оешмасының эш режимы дәүләт оешмасының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән көйләнә.

7.4. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалид укучыларга дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, кирәк булганда махсус шартлар тудырыла, аларга түбәндәгеләр керә:

төркемле һәм индивидуаль коррекция дәресләре үткәрү;

күмәк һәм индивидуаль куллану өчен махсус техник укыту чаралары белән тәэмин итү;

кирәкле техник ярдәм күрсәтүче ассистент (ярдәмче), рус ишарә теле тәрҗемәчесе (сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче), шулай ук психологик-медик-педагогик комиссия рекомендацияләренә туры килгән педагогик хезмәткәрләр белән тәэмин итү;

дәүләт оешмалары биналарына һәм бүлмәләренә керү мөмкинлеген тәэмин итү: дәүләт оешмасына иркен керү һәм чыгу, дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатыннан дәүләт оешмасы территориясендә мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән дәүләт оешмасы хезмәткәрләре ярдәмендә, мәгълүмат йөртүчеләрне тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле тавышлы һәм күренешле мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль шрифты белән рельефлы-нокталы итеп һәм контрастлы фонга башкарылган билгеләр белән кабатлау һ.б.;

алардан башка сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалид булган укучыларга дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкин булмаган яки кыенлаштырылган башка шартлар.

## VIII. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең кадрлар белән тәэмин ителү дәрәҗәсенә таләпләр

8.1. Дәүләт оешмасы штат расписаниесенә туры килгән квалификацияле белгечләр белән һәм укучылар белән комплектланган төркемнәр санына комплектланырга тиеш. Дәүләт оешмасы персоналын комплектлау тәртибе аның уставы белән көйләнә.

8.2. Дәүләт оешмасы хезмәткәрләренә җитәкче, административ-хуҗалык, укыту-ярдәмче, педагогик, медицина һәм хезмәт күрсәтү персоналы керә.

8.3. Педагогик эшчәнлеккә түбәндәге затлар кертелми:

законлы көченә кергән суд карары белән педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм ителгәннәр;

чит ил агентлары;

шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена каршы, җенси кагылгысызлык һәм шәхеснең җенси иреге, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халыкның һәм иҗтимагый әхлакның сәламәтлегенә, дәүләтнең конституциячел корылышы һәм иминлеге нигезләренә каршы, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен (законсыз рәвештә психиатрия стационарына урнаштырылган, яла ягудан һәм мыскыллаудан тыш) һөкем ителгән яисә элегрәк хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә дучар булган затлар (реабилитацияләү нигезләре буенча җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш);

алдан ниятләнгән авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен хөкем карары алынмаган яки көченнән чыгарылмаган;

федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә эшкә сәләтсез дип танылган;

сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган исемлек белән каралган авырулары булган.

8.4. Дәүләт оешмасында хезмәт эшчәнлегенә югары яки урта һөнәри белемгә ия булган, тиешле вазыйфалар өчен билгеләнгән квалификация характеристикалары таләпләренә җавап бирүче затлар кертелә.

8.5. Җитәкче, педагогик персоналның квалификациясен күтәрү биш елга бер тапкырдан да ким булмаган вакытта, өстәмә һөнәри белем бирү учреждениеләрендә, югары уку йортларында һәм тиешле лицензиягә ия булган башка оешмаларда яңадан әзерлек һәм квалификация күтәрү курсларында укыту һәм (яки) стажировка юлы белән башкарыла.

8.6. Медицина хезмәткәрләре администрация һәм педагогик хезмәткәрләр белән беррәттән дәвалау-профилактика чараларын үткәрү, санитария-гигиена нормаларын үтәү, укучыларның туклану режимы һәм сыйфаты өчен җаваплы. Дәүләт оешмасы медицина хезмәткәрләренең эшләве өчен тиешле бүлмә бирә.

8.7. Дәүләт оешмасының медицина хезмәткәрләре бурычларына түбәндәгеләр керә:

укучыларның сәламәтлеге, физик һәм психик үсеше торышын күзәтү, аларга медицина ярдәме күрсәтү;

укучыларның тирәнтен медицина тикшерүләрен, профилактик һәм дәвалау-сәламәтләндерү чараларын оештыру һәм үткәрү, аларның нәтиҗәлелеген бәяләү;

санитария-гигиена һәм эпидемиягә каршы режимны үтәү, туклануны оештыруны һәм сыйфатын, укучыларның уку һәм укудан тыш эшчәнлек режимын үтәүне контрольдә тоту;

укучылар һәм дәүләт оешмасы хезмәткәрләрендә сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыру, шулай ук укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) арасында санитария-агарту эшләре алып бару.

8.8. Җитәкче, административ-хуҗалык, укыту-ярдәмче, педагогик һәм хезмәт күрсәтүче персоналның бурычлары дәүләт оешмасы җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи инструкцияләр белән билгеләнә.

8.9. Дәүләт оешмасы административ-хуҗалык персоналы белән штат расписаниесе һәм санитария нормаларына туры китереп җиһазланырга тиеш.

8.10. Дәүләт оешмасы хезмәткәрләре уставны, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен үтәргә, профессиональ этикага катгый рәвештә иярергә, аларга

йөкләнгән функциональ бурычларны сыйфатлы итеп үтәргә, кешеләрнең яшәү барышында тормыш һәм сәламәтлек куркынычсызлыгы таләпләрен, кагыйдәләрен, нормаларын, хезмәт гигиенасын һәм җитештерү санитариясен үтәргә тиеш; аларның үтәлешен укучылар тарафыннан тәэмин итәргә.

8.11. Дәүләт оешмасында медицина хезмәтен күрсәтүне штаттагы медицина хезмәткәрләре яки сәламәтлек саклау оешмасы медицина хезмәткәрләре, дәүләт оешмасы белән сәламәтлек саклау оешмасы арасында төзелгән медицина хезмәте күрсәтү килешүе нигезендә башкара.

## IX. Дәүләт хезмәтен алу өчен мөрәҗәгать иткәндә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында дәүләт хезмәте алучыларны мәгълүмати тәэмин итү таләпләре

9.1. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт оешмасы турында мәгълүмат торышы Россия Федерациясенең «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 300-1 номерлы законы таләпләренә туры килергә тиеш.

9.2. Дәүләт оешмасын гамәлгә куючы укучыларга һәм аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт оешмалары турында мәгълүматны түбәндәге чыганакларны кулланып җиткерә:

«Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кергән дәүләт оешмасын гамәлгә куючының рәсми сайты;

матбугат чараларында басмалар һәм чыгышлар.

Укучылар һәм аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) дәүләт оешмасын гамәлгә куючыдан дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында бушлай телдән консультация алу хокукына ия.

9.3. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат составына түбәндәгеләр керергә тиеш:

әлеге Стандарт;

дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары турында мәгълүмат;

укучыларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) дәүләт хезмәте сыйфатына йогынты ясау мөмкинлеге турында мәгълүмат;

укучыларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) дәүләт оешмасы хезмәткәрләре белән аралашу чаралары турында мәгълүмат;

укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү мөмкинлеге турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәтләрен нәтиҗәле һәм куркынычсыз күрсәтү кагыйдәләре һәм шартлары;

дәүләт оешмасының гарантия йөкләмәләре.

9.4. Мәгълүмат бирү ысулы һәм тәртибе Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

## X. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, түбәндәгеләр булып тора:

дәүләт оешмасын бетерү яки яңадан оештыру;

дәүләт оешмасына укучыны законсыз кабул итүгә китергән дәүләт оешмасына кабул итү тәртибен бозу очрагында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы инициативасы буенча;

укучының яки балигъ булмаган укучының ата-аналарының (законлы вәкилләренең) инициативасы буенча, шул исәптән укучыны белем бирү программасын үзләштерүне дәвам итү өчен белем бирү эчшчәлеген гамәлгә ашыручы башка оешмага күчерү очрагында.

## XI. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе дәүләт хезмәтен күрсәтү сыйфатының түбәндәге күрсәткечләре белән тасвирлана:

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Исәпләү формуласы | Мәгълүмат чыганагы | Индикаторның чик күрсәткече | Авырлык коэффиценты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Хезмәтнең сыйфаты һәм үтемлелеге белән канәгатьләндерелгән дәүләт хезмәтен алучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) өлеше | процент | $\frac{О_к + О_д}{2 \times О_{общ}} \times 100\%$,<br>монда:<br>$О_к$ – хезмәт сыйфаты белән канәгать булган сораштырылганнар саны;<br>$О_д$ – хезмәт мөмкинлеге белән канәгать булган сораштырылганнар саны;<br>$О_{общ}$ – дәүләт хезмәтен алучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) арасында сораштырылганнарның гомуми саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча | 90 | 5 |
| 2. | Тормыш эшчәнлеге иминлеген бозу очраклары саны | берәмлек | хезмәтне саклау таләпләрен бозу, дәүләт оешмасының матди базасының, янәшә территория торышының канәгатьләнерлек булмавы белән бәйле укучыларның җәрәхәтләнү очраклары исәпкә алына | мониторинг нәтиҗәләре буенча | 0 | 6 |
| 3. | Штатлы хезмәткәрләр белән комплектлану | процент | $\frac{Ч_ф}{Ч_{шр}} \times 100$<br>монда:<br>$Ч_ф$ – оешманың фактик хезмәткәрләр саны;<br>$Ч_{шр}$ – оешманың штат расписаниесе белән каралган хезмәткәрләре саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча «Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә | 100 | 6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | ашыручы оешма турында белешмәләр» ОО-1 номерлы статистик күзәтү формасы һәм аны тутыру буенча күрсәтмәләр (Федераль дәүләт статистика хезмәтенең 2024 елның 12 августында 358 номерлы боерыгы белән расланган) | | |
| 4. | дәүләт хезмәтен алучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре), башка кызыксынган затлар тарафыннан дәүләт оешмасының эшчәнлегенә карата бирелгән нигезле шикаятьләр саны | берәмлек | абсолют күрсәткеч (почта яки электрон почта аша килгән гражданнарның (оешмаларның) хатлары рәвешендә дәүләт оешмасына шикаятьләрне һәм алар буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүматларны анализлау нигезендә билгеләнә) | почта яки электрон почта аша килгән гражданнарның (оешмаларның) хатлары рәвешендә дәүләт оешмасына шикаятьләрне һәм алар буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүматларны анализлау нигезендә | 0 | 9 |
| 5. | Укучылар арасында хокук бозулар һәм җинаятьләр саны | берәмлек | хокук бозулар саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча | 0 | 7 |

## XII. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат стандарты үтәлмәүгә карата шикаятьләр бирү, аларны теркәү һәм карап тикшерү тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибен бозу турында шикаять (алга таба – шикаять) укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан кәгазьдә язмача яки электрон формада дәүләт оешмасына бирелә. Дәүләт оешмасы җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр дәүләт оешмасын гамәлгә куючыга бирелә.

12.2. Дәүләт оешмасы, аның җитәкчесе һәм хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан почта аша, гамәлгә куючының һәм дәүләт оешмасының рәсми сайты, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (www.gosuslugi.ru) яки

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (uslugi.tatarstan.ru) аша бирелергә мөмкин, шулай ук укучыларның ата-аналарын (законлы вәкилләрен) шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

12.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

дәүләт оешмасы һәм аның вазыйфаи затының исеме;

укучының һәм аның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булса), яшәү урыны турында мәгълүмат, шулай ук җавап җибәрелергә тиешле элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булса) һәм почта адресы;

дәүләт оешмасы һәм аның вазыйфаи затының шикаять ителгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүмат;

укучының ата-аналары (законлы вәкилләре) дәүләт оешмасы һәм аның вазыйфаи затының карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәүләренә нигез булган дәлилләр. Укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) үз дәлилләрен раслаучы документларны (булган очракта) яки әлеге документларның күчермәләрен тапшыра алалар.

12.4. Шикаятьне карау шикаятьләрне карау вәкаләтләренә ия булган вазыйфаи зат тарафыннан аны теркәгән көннән башлап 15 эш көне эчендә каралырга тиеш.

Шикаятьне теркәү дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың эш алып бару кагыйдәләренә туры китереп, шикаять килгән көннән башлап өч календарь көннән дә соңга калмыйча башкарыла, әгәр дә дәүләт оешмасы, мәгариф оешмасының вазыйфаи заты документларны кабул итүдән баш тарту яки җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарту яки әлеге төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозу очраклары буенча шикаять бирелгән булса – аны теркәгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

12.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча дәүләт оешмасы түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

шикаятьне канәгатьләндерә;

шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

12.6. Карар кабул ителгән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча, укучының ата-анасына (законлы вәкиленә) язмача һәм аның теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

12.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылган очракта, укучының ата-анасына (законлы вәкиленә) җавапта дәүләт оешмасы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдә ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарылган гамәлләр һәм дәүләт хезмәтен алу максатында укучының ата-анасы (законлы вәкиле) тарафыннан башкарылырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, укучының ата-анасына (законлы вәкиленә) кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне

карап тикшерү буенча вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

12.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрне карау «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә башкарыла.

Судка кадәрге шикаять нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, шулай ук шикаятьне карауның теләсә кайсы стадиясендә укучының әти-әнисе (законлы вәкиле) гамәлдәге законнар нигезендә судка мөрәҗәгать итү хокукына ия.

## XIII. Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе

Дәүләт хакимияте органнары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## XIV. Дәүләт хезмәтен түләүле яки бушлай күрсәтү турында мәгълүмат

14.1. Дәүләт оешмасының интернатында укучыларны карап тоту, шул исәптән укучыларны билгеләнгән нормаларга туры китереп кием, аяк киеме, йомшак инвентарь, шәхси гигиена әйберләре, мәктәп-язу кирәк-яраклары, уеннар һәм уенчыклар, хуҗалык инвентары, туклану белән тәэмин итү һәм аларның хуҗалык-көнкүреш хезмәтен оештыру өчен, дәүләт оешмасын гамәлгә куючы үзе раслаган тәртиптә ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) җыела торган түләүне һәм аның күләмен билгеләргә хокуклы. Гамәлгә куючы күрсәтелгән түләүнең күләмен киметергә яисә аны балигъ булмаган укучыларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) ул билгеләгән очракларда һәм тәртиптә аерым категорияләреннән алмаска хокуклы.

14.2. Дәүләт оешмаларында яшәүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, шул исәптән инвалидлык булган укучыларга дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә.

14.3. Дәүләт оешмаларында яшәми торган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, шул исәптән инвалидлык булган укучылар гамәлгә куючы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты һәм Россия Федерациясе законнары белән каралган башка финанслау чыганаклары хисабына ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин ителә.

14.4. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары өчен спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы интернаты булган дәүләт оешмаларында балаларны тәэмин итү өчен ата-аналардан түләү җыелмый.